Беренче тапкыр әлеге кушымча Орхон текстларында күзәтелә: *ölteçi bodunug tirgürü igittim* (KT D, 29) 'үләчәк халыкны терелттем'; *eki üç biŋ sümüz kelteçimiz bar mu* (T, 14) 'ике-өч мең киләчәк гаскәребез бармы'; *üküş ölteçi anta tirildi* (BK D, 31) 'күп үләчәк анда терелде'; *ölteçiçe sakınıgma türük begler bodun* (BK D, 2) 'үләчәкне уйлаучы төрки халык, бәгләр'. Мисаллардан күренгәнчә, җөмләләрдә -DAçI формасы атрибутив функциядә кулланылган һәм исемләшеп килгән [2: 171].

Орхон язмаларында әлеге кушымча алган фигыльләрнең төрле функцияләрдә кулланылуы күзәтелә. Сөйләү моментыннан соң үтәләчәк эш-хәлләрне белдереп, киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә килә: *tabgaç oguz kıtañ buçegü kabışsar kaltaçı biz* (T, 12-13) 'чинлеләр, кытайлар, угызлар – бу өчәү берләшсә, начар булачакбыз'; *ol yergerü barsar türük bodun ölteçi sen* (KT G, 8) 'ул җирләргә китсәң, төрки халык, үләчәксең'; *sü yorılım tedeçi* 'гаскәр йөртик, диячәк'; *ötüken yış olorsar bengü il tuta olortaçı sen* (KT G, 8) 'өтүкән

ешлыгында булсаң, мәңге ил тотып (идарә итеп) яшәячәксең’ [2: 187-188].

Борынгы уйгур истәлекләрендә ***-дачы*** кушымчалы фигыльләрнең атрибутив функциядә кулланылышы, исемләшү очракларының артуы күзәтелә. Мәсәлән: *törtdin yıŋak erdeçi begler* (U III, 2) ‘дүрт яктан тупланачак бәкләр’; *nom, boşgut boşgundaçı tüzünler* (TT V B, 52) ‘сабак алачак баш күтәрүчеләр’; *kelteçi arkış* (H.-ts., 76) ‘киләчәк кәрван’; *ordu karşı közeddeçi* (U III, 4) ‘урданы күзәтәчәк (кеше)’; *anıŋ utru turdaçı yok* (U IV, 283) ‘аңа каршы торачак юк’ һ.б. Уйгур чорында язылган текстларда кушымчаның юклык формасы - mAdAçI теркәлгән: *sizni* ***ayamadaçı agırlamadaçı*** *yok* (Ht V, 42) ‘сезне олыламаячак, хөрмәтләмәячәк юк’; ***sevmedeçi*** *idi yok* (Suv 579, 12) ‘сөйməячәк хуҗа юк’. Уйгур истәлекләрен өйрәнүче алман галиме Марсел Эрдал да бу чорда -mAdAçI кушымчалы сыйфат фигыльнең исемләшүе һәм контекстта төрле килеш кушымчалары белән кулланылышының ешаюы хакында белдерә [3: 289]. Уйгур дәвере истәлекләрендә кушымчаның киләчәк заман хикәя фигыль формасы буларак кулланылуы да теркәлгән: *aŋ kininte öŋi öŋi adrıltaçılar* (U III, 19) ‘иң соңында (һәр бере) аерым-аерым аерылачаклар’ [4: 106-107].

Караһанлы дәверендә язылган әсәрләрдә ***-дачы*** кушымчасы киләчәк заман сыйфат фигыль формасы буларак характерлана. Мәхмүд Кашгарлы, фигыльдән ясалган сыйфатларны барлаганда, хезмәтендә, ***-дачы*** кушымчасына тукталып, бу кушымчаның угыз, кыпчак, йемәк, йагма, аргу, сувар, пәчәнәк һәм күчмә халыклар телендә фигыльдән сыйфат ясагыч форма булуын аерып күрсәткән [5: 32]. Мисалга түбәндәге үрнәкләр китергән: *bardaçı er* ‘барачак ир’, *keldeçi er* ‘киләчәк ир’. Шулай ук кушымчаның сирәк булса да исемләшкән сыйфат фигыль нигезендә бирелгән үтәүче затны белдерүен искәртә [6: 24]. Ул хезмәтенең кушымчаны өйрәнүгә багышлаган битләрендә «... башка төрки халыклар телендә *tapın-guçı* ‘табынучы’*, yükün-güçi* ‘баш июче’ формасында йөргән фигыльләр угызларның телендә *tapın-daçı , yükün-deçi* шәкелен алыр» (DLT II, 168) дип язган. Әсәренең башка урыннарында теркәлгән *suwgar-daçı* ‘сугаручы’, *todgur-daçı* ‘туендыручы’, *togra-daçı* ‘турауы’ (DLT II, 256) кебек үрнәкләр Мәхмүд Кашгарлының фикерен раслый. Әсәрдә -taçı/-teçi кушымчасы ярдәмендә ясалган *tut-taçı* (DLT II, 296) ‘тотучы’, *bitit-teçi, közet-teçi* (DLT II, 218) ‘язучы’, ‘күзәтүче’һ.б. мисаллар урын алган [7: 215]. Кушымчаның, фигыль нигезенә ялганып, киләчәк заман сыйфат фигыль мәгънәсен белдерүен «Кутадгу Билиг»тә теркәлгән күпсанлы мисалларда күрәбез: *Bilip sözledeçi kişi bar öküş / Anı bildeçi er maŋa ked küsüş* (KB, 207) ‘Белеп сөйләячәк кеше бар күп / Аны аңлаячак ир миңа кадерле’; *Yaruttaçı erni yorık tilni bil* (KB, 162) ‘Инсанны яктыртачак татлы телнең кадерен бел’; *Tilekim söz erdi ay bilge bügü / Kidin keldeçike özüm sözlegü* (KB, 192) ‘Әй галим, хаким, теләгем сүз әйтү иде / Киләчәккә калачак сүзне җиткерү’ [8: 170]. Караһанлы чорында язылган әсәрләрдә кушымчаның киләчәк заман мәгънәсендә кулланылуы шактый чикле: *Yavuz iş uçuz ol isiz boldaçı* (KB, 901) ‘Явыз эш кадерсез, ул һәрвакыт начар булачак’; *Usal bolmagıl ay tirig boldaçı / Tirig bolduŋ erse özüŋ öldeçi* (KB, 1066) ‘Әй тереклектә калачак, усал булма / Терек булсаң да бер көн үләчәксең’ [8: 187].

Борынгы төрки чордан алып караһанлы дәверенәчә сузылган гасыр аралыгында язылган әсәрләр телендә -DAçI кушымчасын еш очратырга мөмкин, аның мәгънә күләме киң булган, киләчәк заман хикәя фигыль, сыйфат фигыль мәгънәләрен белдергән.

Урта төрки чор текстларында бу форма сирәк очрый. Кыпчак нигезле төрки телдә, Хәрәзм, Иске Анадолу өлкәләрендә язылган әсәрләрдә, нигездә, сыйфат фигыль күрсәткече буларак теркәлгән.

Мәсәлән, Хәрәзм төбәгендә язылган «Нәһҗел-Фәрадис» әсәрендә ***-дачы*** кушымчасының сыйфат фигыль мәгънәсе генә теркәлгән: *Ferişteler Taŋrı te'âlâdın peygambar 'asnuŋ kılmış kıldaçı zelletlerini yarlıkatu tileyürler* (NF, 4-4), ‘Фәрештәләр Тәңре тәгаләдән пәйгамбәр галәйһи әс-сәламнең килгән, киләчәк языкларын ярлыкатуны телиләр’; *Peygambar 'asnuŋ kelmiş keldeçi yazukını yarlıkamışdın soŋ magfiretini tilese ummatınga sezâ turur* (NF, 83-17) ‘Пәйгамбәр галәйһи әс-сәламнең килгән, киләчәк языгын ярлыкаганнан соң гафу теләсә, өммәтенә лаек булыр’. Хәрәзм язма истәлеге, тюркологиядә Ибне-Мөһанна сүзлеге буларак танылган өч телле (гарәпчә-төркичә-монголча) «Һилйатул-лисан вә Һулбәтүл-бәйан» сүзлегендә *sıgtaçı* ‘елатучы’ сүзендә -taçı кушымчасы исемләшкән сыйфат фигыль мәгънәсен белдерә [9: 61].

Кыпчак телле әсәрләрдә, асылда, сыйфат фигыль күрсәткече буларак кулланылган: keldeçi ay (T, 28) ‘киләчәк ай’, keldeçi yıl (T,107,

28) ‘киләчәк ел’ [10: 141], *tuvurdaçı kız* (CC, 151, 5) ‘тудырачак кыз’, *kökni, yerni yarattaçı* (CC, 137, 6) ‘күкне, җирне яраткан’ [4: 106], *barçamız öldeçibiz* (V56b, 22) ‘барыбыз үләчәкбез’, *Sunkur bardaçıdır* (V60b, 4-5) ‘Сункур барачактыр’ [11: 196].

Борынгы төрки телдә *-тачы, -тәчи, -дачы, -дәчи* вариантларында теркәлгән кушымчаның иске Анадолу төркичәсе белән язылган текстларда бары яңгырау вариантын очратабыз. XIII-XIV гасырларда язылган «Бәһҗәтүл-Һадаик», «Гарипнамә» истәлекләрендә *-дачы, -дәче* формасы сирәк очрый, ә XV гасыр язмаларында *-деч* кушымчасының киләчәк заман хикәя фигыль, сыйфат фигыль ясавы һәм исемләшү очраклары теркәлгән: *keldeçi yıl* (BH, 143-22) ‘киләсе ел’, *gelmişüŋ geldeçinüŋ ma’budı ol* (APG, 24-5) ‘килгәннең, киләчәкнең табына торган кешесе ул’, *ol kim dirildi öldeçi ol* (BH, 121-5) ‘ул кем терелде, үләчәк ул’ [1: 99], *geldeç yıl* (KŞ. 638; KŞ. 2155) ‘киләсе ел’ [12: 124], *geldeç evsim* (Kesir. XV, 399) ‘телгә киләчәк’ [13].

Тюркологиядә -DAçI кушымчасының төрки язма истәлекләрдә кулланылышын өйрәнүгә бәйле бай чыганак бар. Кемал Әрасланның бу юнәлештә язылган «Eski Türkçe’de İsim-Fiiller» хезмәтендә борынгы төрки, караһанлы дәвере язмаларында -DAçI формасы анализланган. Галим бу формалы фигыльнең аергыч ролендә килүен, исемләшүен һәм контекстта килеш кушымчалары белән төрләнешен, хикәя фигыль мәгънәсендә кулланылышын өйрәнә [14: 61-66]. Галим шулай ук -DAçI кушымчасының үзенчәлекләрен, функцияләрен һәм җөмләдәге күптөрле мәгънә мөнәсәбәтләрен тикшерә [14: 132, 134, 135, 139-151]. М.Мансуроглының «Türkçede -taçı Ekinin Fonksionları» мәкаләсендә борынгы һәм урта төрки чор язма истәлекләрендә кушымчаның мәгънә мөмкинлекләре барланган, борынгы төрки һәм урта төрки чорларда язылган әсәрләр теленнән үрнәкләр китерелгән [4: 105-108]. Нәсрин Байрактарның «Türkçede Fiilimsiler» монографиясендә -DAçI кушымчасының киләчәк заман сыйфат фигыль мәгънәләре [1: 96-99] һәм сыйфат фигыльнең исемләшү күренеше өйрәнелгән [1: 61-66].

Зәйнәп Коркмазның бу юнәлештә алып барган эзләнүләре бик нәтиҗәле. Ул Орхон-Енисей язуларында теркәлгән -тачы, -тәче, -дачы, -дәче кушымчасының киләчәк заман мәгънәсенә, шулай ук, исемләшеп, төрле килеш кушымчалары белән кулланылуына күзәтү ясый, бу форманың Мәхмүд Кашгарлы сүзлегендә кимүен күрсәтә һәм аның иске Анадолу төркичәсендә мәгънә мөмкинлекләрен ачыклый [7: 215]. Галим «Kaşgarlı Mahmud ve Oğuz Türkçesi» мәкаләсендә бу проблемага янә әйләнеп кайта, сүзлектә урын алган әлеге кушымчаның традицион угыз теле үзенчәлеге булуын ассызыклый [15: 252-253]. З.Коркмаз фикерен куәтләп, яңа мисаллар белән исбатлап язылган Г.Гүлсәвин мәкаләсе шулай ук игътибарга лаек [16: 15]. Мәмлүк-кыпчак Мисыр дәүләтенең язма истәлеге булган «Китабе мәҗмуге тәрҗемани төрки вә гаҗами вә магули вә фарси» сүзлегендәге -дачы кушымчасы белән ясалган сүзләргә Мәләк Өзьетген дә игътибар иткән, мисаллар китергән: *keldeçi ay, keldeçi yıl.* Мәмлүк җирлегендә язылган башка әсәрләрдә, мәсәлән «Kitâbu’l-İdrâk Li Lisâni’l-Etrâk» сүзлегендә теркәлмәгән -daçı/-deçi кушымчасын төрекмән (угыз) телләре өчен хас форма дип саный [11: 197].

Борынгы төрки һәм урта төрки чорда иҗат ителгән әсәрләрнең телендә күп функциягә ия булган -дачы, -дәче, -тачы, -тәче формасы соңрак чорда язылган истәлекләр телендә очрамый. Мәҗдут Мансуроглу фикеренчә, бу кушымча – тар бер заман, ягъни борынгы төрки чордан урта гасыр язма истәлекләре теле өчен генә хас булып, төрки телләрдә кулланылыштан төшеп калган архаик форма. Бары тик татар теленең кайбер сөйләшләрендә генә -дачы кушымчасы сакланып калган, ди галим [4: 105]. Ә.Р.Тенишев бу күрсәткечнең караимнар һәм алтай төркиләре телендә очравын яза. Алтай төркиләрендә *алдачы* сүзе ‘үлем фәрештәсе, явыз рух’, караимнарда *билдәчи* сүзе ‘белгеч, галим’ мәгънәләрендә сакланган [17: 468].

Мәҗдут Мансуроглының ***-дачы*** кушымчасының бүгенге төрки халыклардан бары татар сөйләшләрендә генә очравы хакында әйтелгән фикере безне яңа эзләнүләргә этәрде. Чыннан да, борынгы төрки истәлекләрендә актив кулланылышта булган әлеге кушымчаның татар теленең мишәр диалектында гына саклануын һәм күп функциягә ия булуын ачыкладык.

Төрки телләрне төркемләгәндә, татар телен кыпчак, төньяк, төньяк-көнбатыш, Тау төркеменә кертеп карыйлар. XIX гасырның урталарында әкренләп җанлы сөйләм теле үзенчәлекләренә йөз тоткан татар әдәби теле XX гасыр башларына үзенең төзелеше белән бер-беренә якын торган диалектлар нигезендә тәмам формалашып бетә. Татар әдәби теленең нигезен урта һәм көнбатыш (мишәр) диалект-

лары тәшкил итә. Себер татарлары теле әдәби телгә карата пассив диалект булып торса да, татар әдәби теле белән якынлык күрсәтә [18: 17]. Мишәр диалекты түбәндәге сөйләшләрдән тора: 1) сергач сөйләше (Түбән Новгород өлкәсендә), 2) чистай сөйләше (Татарстанда һәм Самара өлкәсендә), 3) чүпрәле сөйләше (Татарстанда һәм Чувашиядә), 4) мәләкәс сөйләше (Ульяновск өлкәсендә), 5) хвалын сөйләше (Ульяновск өлкәсендә), 6) темников сөйләше (Мордовиянең көньяк-көнбатышында), 7) ләмбрә сөйләше (Мордовиянең көньяк-көнчыгышында), 8) кузнецк сөйләше (Пенза, Саратов һәм Волгоград өлкәләрендә), 9) мордва-каратай сөйләше (Татарстанда), 10) байкыбаш сөйләше (Башкортостанда), 11) шарлык сөйләше (Оренбург өлкәсендә), 12) стәрлетамак сөйләше (Башкортостанда) [19: 37].

Мишәр һәм урта диалектлар үзара шактый якын. Мишәр сөйләшләрен ике типка – ч-лаштыручыларга һәм ц-лаштыручыларга аералар. Ч-лаштыручы төркемгә – темников, ләмбрә, кузнецк, хвалын, мәләкәс, мордва-каратай һәм шарлык; ц-лаштыручы төркемгә сергач, чүпрәле, байкыбаш һәм стәрлетамак сөйләшләре керә. Чистай сөйләше катнаш, анда ч-лаштыру һәм ц-лаштыру күренешләре күзәтелә [20: 9-10].

Татар теленең мишәр сөйләшләрендә сыйфат фигыльнең -дач кушымчасы белән ясалу очрагы сакланган. Бигрәк тә чистай, чүпрәле, хвалын, кузнецк, сергач сөйләшләрендә ул фәкать бул- фигыленең нигезенә ялганып, *булдач/булдац* рәвешендә кулланыла. Мишәр диалектларын монографик планда өйрәнгән галимә Л.Т.Мәхмутова *-дач, -дац* кушымчасының туганлык, якынлык мәгънәсендәге сүзләргә ялгануына игътибар иткән: kilen buldaç ‘килен булачак’, kiyew buldaç ‘кияү булачак’, koda buldaç ‘кода булачак’ һ.б; eti buldaç ‘әти булачак’, apa/seŋel buldaç ‘апа/сеңел булачак’. *Булдач* сыйфат фигыле исемләшеп, тартым кушымчалары ала: kilen buldaç-ım ‘килен булачагым’, kilen buldaç-ıŋ ‘килен булачагың’, kilen buldaç-ı ‘килен булачагы’. [21: 80].

Ф.Юсупов бу форманы киләчәк заман сыйфат фигыль күрсәткече буларак карый, туганлык белән бәйле «кияү булдач кеше», «килен булдач» тезмәләрендә кулланылышын күрсәтә [22: 80]. Л.Җәләй дә ***-дачы*** кушымчасы белән ясалган сыйфат фигыльнең хәзерге телдә мәгънәсе тараюын, мишәр сөйләшләрендә гаилә төзелешенә караган берничә сүздә саклануын билгели: бу аның кияү булдачы, кәләш булдачы һ.б. [23: 241].

**-дач кушымчасының мишәр сөйләшләрендә кулланылышы**

**I. -дач кушымчалы сыйфат фигыльнең исемләшүе**

**I.1. Баш килештә һәм тартым кушымчалары белән кулланылышы.**

-дач формасы тартым кушымчасы белән кулланылып, җөмләдә ия яки тәмамлык булып килә: *Barıgız, kan'na **buldaçısın** da küregez* (TXS II, 233) ‘Барыгыз, кайнана булачакны күрегез’; Bu *kilen **buldaçları*** bula inde (OİTD, 180) ‘Бу килен булачаклары була инде’; *Kiyew **buldaçı*** da bik uŋgan inde (OİTD, 180) ‘Кияү булачак та бик уңган инде’; *Kan'n'a **buldaçları*** da big yej bit ele (OİTD, 180) ‘Кайнана булачаклары да бик яшь бит әле’; *Xatın **buldaçı*** tenle kitken istansaga, *ir **buldaçı**-*igençe kenne (OİTD, 180) ‘Хатын булачак төнлә киткән станциягә, ир булачагы икенче көнне’; *Savit persidetele **buldaçı*** katını (OİTD, 180) ‘Авыл советы рәисе булачак(ның) хатыны’.

**I.2. Килеш кушымчалары белән кулланылышы. *-дачы*** формалы сыйфат фигыль исемләшә һәм төрле килеш кушымчалары белән кулланыла, субьект, обьект мөнәсәбәтләрен белдерә. Мисаллар:

*Minem yaktan dürt par ertsi kilde ertsiler kildeler ilahi kadir mine yeş kilen **buldatsını** kütereb alıp agişek aldına kertep birdeler* (MTD, 105) ‘Минем яктан дүрт пар (әрчи) кунак килде, әрчиләр килделәр, илаһи кадир, мине, яшь килен булачакны, күтәреп алып ак ишек алдына кертеп бирделәр’;. *Minĭm kilen **buldatska** tege atrisnı birermen* (MTDY, 90) ‘Минем килен булачакка теге отрезны (кисәкне) бирермен’. Tırdı kene-tene şul minem *kilen **buldaçlarda*** (OİTD, 180) ‘Көне-төне минем килен булачакта торды’.

**I.3. Күплек сан кушымчалары белән кулланылышы.** -дач кушымчасына күплек формасы ялганып, субьект мөнәсәбәтен белдерә: *Tuyga koda **buldaçlar** kile digenner ide* (MTDY, 90) ‘Туйга кода булачаклар килә дигәннәр иде’.

**I.4. Бәйлекләр белән кулланылышы.** Тупланган материаллардан күренгәнчә, *-дач* кушымчалы исемләшкән сыйфат фигыль бәйлекләр белән дә кулланыла. Мәсәлән: *Kiyew **buldats** belen berge kat'tılar* (TXS II, 203) ‘Кияү булачак белән бергә кайттылар’. *Kilen **buldaçım** belen Çistayga bardık* (MTDY, 90) ‘Килен булачагым белән Чистайга бардык’.

**II. Киләчәк заман сыйфат фигыль функциясендә кулланылышы**

**II.1.** *-дач* кушымчасы ярдәмендә ясалган фигыльнең киләчәк заман мәгънәсе сөйләшләрдә сирәк очрый. Бу форманы тикшерү аның сыйфат фигыль мәгънәсендә һәм исемләшкән хәлдә кулланылышын күрсәтә [24: 168]:

*Birnege ü bizeklere, almalı sölgeler, tsarşaw alıp kile kelen* ***buldats*** *keşe* (TM, 57) ‘Бирнәгә өй бизәкләр, чаршау алып килә килен булачак кеше’.

*Minem yaktan dürt par ertsi kilde ertsiler kildeler ilahi kadir mine yeş kilen* ***buldatsını*** *kütereb alıp agişek aldına kertep birdeler* (MTD, 105) ‘Минем яктан дүрт пар (әрчи) кунак килде, әрчиләр килделәр, илаһи кадир, мине, яшь килен булачакны, күтәреп алып ак ишек алдына кертеп бирделәр’. *Barıgız, kan'na* ***buldaçısın*** *da küregez* (TXS II, 233) ‘Барыгыз, кайнана булачагын да күрегез’. *Kiyew* ***buldats*** *belen berge kat'tılar* (TXS II, 203). ‘Кияү булачак белән бергә кайттылар’. *Kilen* ***buldaçım*** *belen Çistayga bardık* (MTDY, 90) ‘Килен булачагым белән Чистайга бардык’. *Tuyga koda* ***buldaçlar*** *kile digenner ide* (MTDY, 90) ‘Туйга кода булачаклар килә дигәннәр иде’. *Minĭm kilen* ***buldatska*** *tege atrisnı birermen* (MTDY, 90) ‘Минем килен булачакка теге отрезны (кисәкне) бирермен’. *Savit persidetele* ***buldaçı*** katını (OİTD, 180) ‘Авыл советы рәисе булачакның хатыны’.

**II.2. Заманга мөнәсәбәтсез, гомумән предметка хас булган билгене белдерү очраклары:**

Tırdı kene-tene şul minem *kilen* ***buldaçlarda*** (OİTD, 180) ‘Көне-төне минем килен тиешлеләрдә торды’. *Bu kilen* ***buldaçları*** *bula inde* (OİTD, 180) ‘Бу килен тиешлеләре була инде’. *Kiyew* ***buldaçı*** *da bik uŋgan inde* (OİTD, 180) ‘Кияү тиешлеләре бик уңган инде’. *Kan'n'a* ***buldaçları*** *da big yej bit ele* (OİTD, 180) ‘Кайнана тиешлеләре дә бик яшь бит әле’. *Xatın* ***buldaçı*** *tenle kitken istansaga, ir* ***buldaçı****-igençe kenne* (OİTD, 180) ‘Хатын тиешлеләре төнлә киткән станциягә, ир тиешлесе икенче көнне’.

Мишәр сөйләшләрендә *-дач* кушымчасына тышкы яктан охшаш һәм мәгънәләре белән якын торган *-дакчы, -дакцы* формалары саклануына да игътибар иттек. Л.Т.Мәхмүтова бу кушымчаны борынгы төрки телдә кулланылган *-дукчы* формасы белән бәйләп карый [21: 181]. Әлеге кушымчалар бары бул- фигыле белән генә очрый. Ул аергыч функциясендә, исемләшкән хәлдә кулланыла:

*Kiyew* ***buldakçı*** *keşebez armiyege kitte* (MTDY, 90) ‘Кияү булачак кешебез армиягә китте’. *Kaynana* ***buldakçıga*** *külmek yawlık namazlık bit sörtkeçe bireler* (MTD, 110) ‘Кайнана булачакка күлмәк, яулык, намазлык, бит сөрткеч бирәләр’. *Mına kiyew* ***buldaktsı*** *keşe de kilde* (TXS II, 233) ‘Миңа кияү булачак кеше дә килде’.

Йомгаклап әйткәндә, борынгы төрки һәм урта төрки дәвердә иҗат ителгән истәлекләр телендә ***-дачы, -дәче, -тачы, -тәче*** кушымчасы актив кулланылган, күп функциягә ия булган, контекстта, фигыльләргә ялганып, аергыч функциясендә, исемләшкән хәлдә һәм киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә килгән. Урта төрки дәвердән соң язылган әсәрләр телендә бу форма теркәлмәгән, архаиклашып, кулланылыштан төшеп калган. Хәзерге чорда ***-дачы*** кушымчасы төрки телләрдән бары тик татар теленең мишәр диалектында: чистай, чүпрәле, хвалын, кузнецк һәм сергач сөйләшләрендә бул- нигезенә ялганып, туганлык мәгънәсе салынган тезмә сүзләрдә генә сакланып калган. Борынгы төрки текстларда кушымчаның дүрт варианты да теркәлгән булса, мишәр сөйләшләрендә бары *-дач/-дац* формасы гына күзәтелә. Мисаллардан күренгәнчә, *-дач/-дац* кушымчалы сыйфат фигыль исемләшә һәм төрле килеш кушымчалары белән кулланыла.

Мәхмүд Кашгарлы ***-дачы*** кушымчасының угыз, кыпчак, йемәк, йагма, аргу, сувар, пәчәнәк һәм күчмә халыклар телендә очравын билгеләсә, борынгы һәм урта төрки чорларда әлеге күрсәткеч барлык төрки телләр өчен уртак формага әверелә. Зәйнәп Коркмаз фикеренчә, ***-дачы*** формасы, классик төрки әдәби телнең угыз телләре күрсәткече буларак, яңа төрки чорга кадәр кулланылышта булган. Урта гасырдан соң төрки язма истәлекләр телендә очрамаган бу кушымча безнең көннәрдә кыпчак төркеменә кергән татар теленең мишәр диалектында сакланып калган. Мишәр сөйләшләрендә яшәвен дәвам иткән борынгы ***-дачы*** формасы һәм башка архаик тел күренешләре төрки телләрнең формалашуына кагылышлы кайбер мәсьәләләрне яңача фәнни нигездә аңлатырга мөмкинлек бирә.

**Шартлы кыскартулар**

APG – Bedri Noyan (Çev.). Aşık Paşa-yı Velî Garipnâme. Ardıç Yay. Ankara, 1998. 422 s.

BH – Mustafa Canpolat. Behçetü'l-Hadaik fi Mev'izeti'l-Halâik (Basılmamış Doktora Tezi). Ankara, 1965. 426 s.
BK D – Bilge Kağan Yazıtı Doğu Cephesi. Muharrem Ergin, Orhun Abideleri, Bogaziçi Yay. İstanbul, 1991. 191 s.
CC – K. Grönbech. Komanisches Wörterbuch. Kopenhagen, 1942. 238 s.
H.-ts. – A. von Gabain. Die uigurische Übersetsug der Biographie Hüen-tsang-Biographie. SPAW. 1938. XXIX. Berlin, 1938. 506 s.
Kesir. XV. – Muhammet Yelten, Şirvanlı Mahmud. Târih – i İbn – i Kesîr Tercümesi (Giriş – İnceleme – Metin – Sözlük). 1998. 366 s.
KT D – Kül Tigin Yazıtı Doğu Cephesi. Muharrem Ergin, Orhun Abideleri, Bogaziçi Yay. İstanbul, 1991. 191 s.
KT G – Kül Tigin Yazıtı Güney Cephesi. Muharrem Ergin, Orhun Abideleri, Bogaziçi Yay. İstanbul, 1991. 191 s.
MTD – Материалы по татарской диалектологии. Казань: Тат. кит. нәшр., 1990. 131 с.
MTDY – Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка. Казан: Фән, 2004. 592 с.
NF – Nehcü'l-Ferâdis. I-II Metin-Tıpkıbasım (Yay. Semih Tezcan-Hamza Zülfikar). TDK Yay. Ankara, 2004. 758 s.
OİTD – Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект татарского языка. М.: Наука, 1978. 270 с.
Suv – W. Radloff, S. Malov. Suvarnaprabhasa. Sutra zolotogo bleska. I-II. Bibliotheca Buddhica, XVII. Sanktpeterburg, 1913. 713 s.
T – Tonyukuk Yazıtı. Muharrem Ergin, Orhun Abideleri, Bogaziçi Yay. İstanbul, 1991. 191 s.
TM – Баязитова Ф.С. Мишәр диалекты. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе. Саранск, 2003. 286 б.
TT V B – W. Bang-G, Rachmatı-A. von Gabain. Türkische Turfan-Texte. Berlin, 1931. 402 s.
TTDS 1969 – Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. 644 б.
TTDS 1993 – Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. 459 б.
TXS II – Татар халык сөйләшләре. II том. Казан: Мәгариф, 2008. 496 б.
U III – F. W. K Müller. Uigurica III. Berlin, 1922. 336 s.
U IV A – A. von Gabain. Uigurica IV. Berlin, 1931. 298 s.

**Әдәбият**

1. *Nesrin Bayraktar*. Türkçede Fiilimsiler. TDK Yay. Ankara, 2004. 397 s.
2. *Talat Tekin*. Orhon Türkçesi Grameri. İstanbul, 2003. 272 s.
3. *Marcel Erdal*. A grammar of Old Turkic. Brill-Leiden-Boston, 2004. 575 s.
4. *Mecdut Mansuroğlu*. Türkçede -taçı Ekinin Fonksionları. İstanbul Ü. Edebiyat Fak. Türk Dili ve Ed. Dergisi, VII (1-2), 1956. s. 105-108.
5. *Kaşgarlı Mahmud*. Divanü Lûgat-it-Türk Tercümesi. II (Çev. Besim Atalay). TDK Yay. Ankara, 1992. 366 s.
6. *Kaşgarlı Mahmud*. Divanü Lûgat-it-Türk Tercümesi. I (Çev. Besim Atalay). TDK Yay. Ankara, 1992. 530 s.
7. *Zeynep Korkmaz*. Eski Türkçedeki Oğuzca Belirtiler // Türk Dili Üzerine Araştırmalar. C. 1. TDK Yay. Ankara, 2005. s. 205-216.
8. *Necmettin Hacıeminoğlu*. Karahanlı Türkçesi Grameri. TDK Yay. Ankara, 2003. 214 s.
9. İbni-Mühennâ Lûgati (Haz. Aptullah Battal). TDK Yay. Ankara, 1988. 109 s.
10. *Ali Fehmi Karamanlıoğlu*. Kıpçak Türkçesi Grameri. TDK Yay. Ankara, 1994. 164 s.
11. *A. Melek Özyetgin*. Ebû Hayvan «Kitâbû'l-İdrâk li Lisâni'l-Etrâk, Fiil». KÖKSAV Yay. Ankara, 2001. 798 s.
12. *Gürer Gülsevin*. Eski Ekler. TDK Yay. Ankara, 1997. 156 s.
13. Tarama Sözlüğü. http://www.tdkterim.gov.tr/tarama/?kelime=gelde% E7&kategori =veritm
14. *Kemal Eraslan*. Eski Türkçe'de İsim-Fiiller. İstanbul, 1980. 174 s.
15. *Zeynep Korkmaz*. Kaşgarlı Mahmud ve Oğuz Türkçesi // Türk Dili Üzerine Araştırmalar. C. 1. TDK Yay. Ankara, 2005. s. 241-253.
16. *Gürer Gülsevin*. Köktürk Bengü Taşlarındaki Oğuzca Özellikler. Kardeş Ağızlar (Türk Lehçe ve Şiveleri Dergisi). C. 7. Ankara, 1998. s. 12-18.
17. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология. М.: Наука, 1988. 557 с.
18. *Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле. Казан: Мәгариф, 1994. 320 б.
19. Татар грамматикасы. Т. I. М.: ИНСАН; Казань: Фикер, 1998. 512 б.
20. Современный татарский литературный язык. М.: Наука, 1969. 384 с.
21. *Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект татарского языка. М.: Наука, 1978. 270 с.
22. *Юсупов Ф.Ю.* Морфология татарского диалектного языка. Казан: Фән, 2004. 592 с.
23. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан: Фикер, 2000. 288 б.
24. *Шәмгунова Р.Р.* Чистай сөйләшенең морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре // Материалы по татарской диалектологии. Выпуск 2. Казань, 1962. с. 163-201.

# СЛЕДЫ ДРЕВНЕТЮРКСКОГО ЯЗЫКА В ТАТАРСКИХ ДИАЛЕКТАХ: ФУНКЦИОНИРОВАНИЕ АФФИКСА -*ДАЧЫ*

**Эржан Алкая,**
Фратский университет,
Турция, г.Элазыг, университетский городок Р-2, №:8,
ealkaya16@gmail.com

В татарском языке, относящемся к кипчакской группе тюркской семьи языков, выделяются три диалекта: средний, западный (мишарский) и восточный (язык сибирских татар). Среди татар, проживающих в Поволжско-Уральском регионе, представители мишарского диалекта занимают второе место по численности после казанских татар. В основе татарского литературного языка лежит средний диалект, однако в развитии языка мишарский диалект и его говоры также занимают важное место. Несмотря на близость мишарских говоров к литературному языку, в них наблюдаются диалектные особенности и сохранение древних языковых явлений.

В данной статье рассматриваются особенности говоров мишарского диалекта, представители которого играли важную роль в формировании татарского народа и в настоящее время проживают в разных регионах России. Исследуются сохранение и особенности употребления в данных говорах аффикса –дачы, зафиксированного в языке древнетюркских письменных источников.

**Ключевые слова:** аффикс -*дачы*, татарский язык, мишарский диалект, тюркский язык, древнетюркский язык.